| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.1.2023 Баулы шәһәре №229

2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына
Баулы муниципаль районы
социаль-икътисади үсешенең
төп күрсәткечләрен фаразлау турында

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы Э. С. Мингалиеваның «Баулы муниципаль районының 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына социаль-икътисади үсешенең төп күрсәткечләре фаразы турында» докладын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң Баулы муниципаль районы Советы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты, шәһәр хезмәтләре тарафыннан төрле милек формасындагы предприятиеләр белән берлектә 2023 елда районның социаль-икътисади үсешен тәэмин итү буенча, халыкның тормыш-көнкүреш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән, билгеле бер эш башкарылуын билгеләп үтә.

Баулы муниципаль районының 2023 елгы социаль-икътисади үсешенең төп параметрларын анализлау түбәндәге бәяләү нәтиҗәләрен күрсәтте:

- тулаем территориаль продукт 55,0 млрд. сум тәшкил итә;
- төп капиталга инвестицияләр – 6,1 млрд. сум;
- авыл хуҗалыгы продукциясе күләме – 2,8 млрд. сум;
- җитештерелгән һәм җибәрелгән продукция, эшләр һәм хезмәтләр күләме –13,9 млрд. сум.

Шәһәр һәм район предприятиеләре, оешмалары, учрежденииеләре халыкка 371,6 млн. сумлык түләүле хезмәт күрсәтәчәк. Ваклап сату товар әйләнеше 5,9 млрд. сум тәшкил итәчәк.

Саналган параметрлардан һәм 2023 елга Баулы муниципаль районы үсеш тенденцияләреннән чыгып, 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразы формалаштырылды.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елга социаль-икътисади үсешнең башлангыч йомгаклары турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (1-нче номерлы кушымта)

2. 2024 елга һәм 2025 -2026 еллар план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсешенең төп параметрларын расларга (2-нче номерлы кушымта).

3. Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә барлык милек формаларын тәкъдим итәргә:

- 2024 елга һәм 2025 - 2026 еллар план чорына социаль-икътисади үсешнең төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- эшчәнлекне җитештерү куәтләрен нәтиҗәле куллануга юнәлтү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, хезмәт шартларын яхшырту һәм эшләүчеләрнең сәламәтлеген саклау, хезмәт хакын вакытында түләүне тәэмин итү, эш урыннарын кыскартуга юл куймау;

- реаль хезмәт хакын арттыру һәм аның дәрәҗәсен минималь хезмәт хакы күләменнән түбән төшерүгә юл куймау буенча чаралар күрергә.

4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына:

- халыкның тормыш-көнкүреш сыйфатын яхшыртуга көч юнәлдереп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисади үсешен тәэмин итәргә;

- күрсәтелгән мөмкинлекләр һәм икътисади үсеш перспективалары кысаларында, бюджет челтәрен оптимальләштерү, энергияне сак тоту һәм энергоемкостьларны киметү, социаль өлкә, торак-коммуналь хуҗалык тармакларында бюджеттан тыш юнәлешләрне үстерү буенча чаралар күрергә.

5. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров

Татарстан Республикасы

Баулы муниципаль район
Советының
2023 елның___ __номерлы
карарына
1-нче номерлы кушымта

Баулы муниципаль районының 2023 елның узган чорындагы социаль-икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2023 елга Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсешенең көтелгән

# НӘТИҖӘЛӘРЕ

| Күрсәткечләр | 2023 январь-июнь | 2023 оценка |
|---|---|---|
| I. Макроикътисади күрсәткечләр | | |
| 1. Тулаем территориаль продукт (төп бәядә), млн. сум. | - | 54963,6 |
| 2. Җибәргән продукция күләме (эшләр, хезмәтләр), млн. сум. | 6051,1 | 13912,6 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, узган елга % да | 101,8 | 101,4 |
| 4. Барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | - | 2812,2 |
| 5. Барлык финанслау чыганаклары хисабына төп капиталга инвестицияләр күләме, млн. сум. | 2547,1 | 6085,3 |
| 6. Торак йортларны файдалануга тапшыру, мең. кв. м | 9,326 | 15,0 |
| 7. Кече һәм урта предприятиеләр, шул исәптән микропредприятиеләр әйләнеше, млн. сум. | - | 3071,5 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 2199,5 | 4432,4 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына), мең кеше | 0,56 | 0,35 |
| 10. Икътисади актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,3 | 0,2 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | |
| 1. Җан башына уртача айлык керем, сум | 37469,1 | 38250,0 |
| узган елга % да | 114,5 | 105,4 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (уртача елына), сум. | 49849,0 | 51187,24 |
| узган елга % да | 108,2 | 110,6 |
| III. Сәнәгать | | |
| Сәнәгать продукциясенең мөһим төрләрен җитештерү: | | |
| Нефть, млн.т. | 1,1 | 2,1 |
| III. Агросәнәгать комплексы | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | |
| Ашлык (эшкәртелгәннән соң авырлыкта), мең. т. | - | 38,75 |
| Ит (терлек һәм кош тере авырлыкта), мең. т. | 0,8 | 1,5 |

| Күрсәткечләр | 2023 январь-июнь | 2023 оценка |
|---|---|---|
| Сөт, мең. т. | 6,7 | 13,0 |
| IV. Кулланучылар базары | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 3270,4 | 5924,1 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум. | 177,4 | 371,6 |
| 3. Җәмәгать туклануы әйләнеше, млн. сум. | 73,5 | 156,1 |

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль район
Советының
2023 елның___ __номерлы
карарына
2 –нче номерлы кушымта

# 2024 ел һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсеше фаразы

| Күрсәткечләр | 2024 фаразлау | 2025 фаразлау | 2026 фаразлау |
|---|---|---|---|
| I. Макроикътисади күрсәткечләр | | | |
| 1. Тулаем территориаль продукт (төп бәядә), млн. сум. | 56696,6 | 59304,6 | 62470,4 |
| 2. Җибәргән продукция күләме (эшләр, хезмәтләр), млн. сум. | 14589,4 | 15445,0 | 16582,4 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, узган елга % да | 101,6 | 101,1 | 101,5 |
| 4. Барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | 3300,9 | 3418,1 | 3526,5 |
| 5. Барлык финанслау чыганаклары хисабына төп капиталга инвестицияләр күләме, млн. сум. | 6340,9 | 6619,9 | 6957,5 |
| 6. Торак йортларны файдалануга тапшыру, мең. кв. м | 13,0 | 13,0 | 13,0 |
| 7. Кече һәм урта предприятиеләр, шул исәптән микропредприятиеләр әйләнеше, млн. сум. | 3228,2 | 3405,7 | 3603,2 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 4689,5 | 4980,2 | 5308,9 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына), мең кеше | 0,35 | 0,35 | 0,35 |
| 10. Икътисади актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,2 | 0,2 | 0,2 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | | |
| 1. 1. Бер кешегә уртача айлык керем, сум | 40545,0 | 42815,5 | 45127,6 |
| узган елга % ларда | 106,0 | 105,6 | 105,4 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (бер елга уртача), сум. | 55392,0 | 59254,64 | 63364,48 |
| узган елга % да | 108,2 | 107,0 | 106,9 |
| III. Агросәнәгать комплексы | | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | |
| Ашлык (эшкәртелгәннән соң авырлыкта), мең. т. | 2199.575,0 | 76,0 | 77,0 |
| Ит (терлек һәм кош тере авырлыкта), мең. т. | 1,6 | 1,7 | 1,8 |
| Сөт, мең. т. | 13,2 | 13,5 | 15,5 |
| IV. Кулланучылар базары | | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 6279,5 | 6662,5 | 7029,0 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум. | 385,7 | 401,1 | 417,2 |

| Күрсәткечләр | 2024 фаразлау | 2025 фаразлау | 2026 фаразлау |
|---|---|---|---|
| 3. Җәмәгать туклануы әйләнеше, млн. сум. | 162,9 | 169,4 | 177,7 |